КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1744

«2024 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын раслау турында

Татарстан Республикасында гражданнарны һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү һәм дәүләт программаларының гамәлдәге кайбер чаралары кысаларында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру чараларын финанслашуны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2024 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын расларга**.**

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын раслау турында» 2022 ел, 27 декабрь, 1425 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 31 октябрь, 1374 нче карарының 9 пункты;

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 декабрь, 1744
нче карары белән расланды

«2024 елга Татарстан Республикасында торак белән тәэмин итүдә гражданнарга дәүләт ярдәме» программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2024 елга Татарстан Республикасында гражданнарга торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Программаның максаты | Гражданнарның торакка конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | Татарстан Республикасында керемнәр дәрәҗәсе төрле булган гражданнарны бәясе буенча һәркем алырлык торак белән тәэмин итүнең эффектив системасын оештыру, гражданнар өчен торакның һәркем алырлык булуын тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек яки наем хокукында даими һәм вакытлыча тору өчен нәтиҗәле торак базарын булдыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2024 ел |
| Программаны үтәүче | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды – махсуслаштырылган оешмасы (Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2005 елның 23 июнендәге ПУ-265 номерлы Указы) |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында Программа чараларын кимендә 17 757,423 млн.сум күләмендә финанслау.<br>2. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка социаль ипотека системасында хокукны гамәлгә ашыручы гаиләгә бала туу вакытында, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренчел һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә Программаны финанслауның каралган күләмнәре нигезендә дәүләт ярдәмен күрсәтү 700,0 млн. сум күләмендә.<br>3. Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру һәм җир кишәрлекләрен махсуслаштырылган оешмага түләүсез файдалануга бирү.<br>Татарстан Республикасы территориясендә Программаны башкаручы төзегән торак күләме барлыгы 161,7 мең кв.метр тәшкил итәргә тиеш. |
| Программаны финанслау чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итү чараларын финанслауга юнәлтелгән чыгымнарның гомуми күләме 18 457,423 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы оешмалары түләүләре исәбеннән Татарстан Республикасы оешмалары һәм Программаны үтәүче арасында төзелгән иганә шартнамәләре һәм килешүләр нигезендә Программа чараларын үтәүгә – 10 961,405 млн.сум;<br>Программаны үтәүче акчасы исәбеннән – 6 796,018 млн.сум, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фонды белән төзелгән иганә шартнамәсе нигезендә Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен булдыруны финанслауга – 6,319 млн.сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән балалары туган яки уллыкка (кызлыкка) алынган гаиләләргә |

| | |
|---|---|
| | сатып алына торган торак өчен башлангыч һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә – 700,0 млн.сум |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | Эшчәнлекне тикшереп тору һәм координацияләү Программаның координаторы тарафыннан тәэмин ителә |

## I. Проблеманың тасвирламасы

2005 елдан «Татарстан Республикасында торак төзелешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак төзелешен үстерү гамәлгә ашырыла.

Программаның төп юнәлеше – Татарстан Республикасы халкына социаль ипотека системасында, шулай ук торак урыннарын махсуслаштырылган оешма аша сатып алу теләген белдергән гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән кулланучылар кооперативлары әгъзаларына, гражданнарга һәм юридик затларга ипотека кредиты бирү. Программа кысаларында торак төзелешен үстерү һәм республика халкын һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү максатыннан торак йортлар төзелешен һәм төзелешен уртак финанслауга акчалар җәлеп ителә.

Аерым гражданнарның керемнәре түбән булганда һәм финанс институтларының тотрыклылыгына ышанычлары булмаганда, Программаны гамәлгә ашыру кыска вакыт эчендә икътисадның реаль секторына торак шартларын яхшыртуга тупланган халык акчаларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Махсуслаштырылган оешмада торак урыннары алырга теләк белдергән гражданнар, аларны киң колачлы төзелешкә кертеп, торак мәсьәләсен хәл итүнең уникаль ысулын сатып алалар. Программа дәүләт хакимияте органнарының тыгыз хезмәттәшлегендә гамәлгә ашырыла.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм аларны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның максаты – торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның торакка конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру.

Программаның бурычы – Татарстан Республикасында гражданнарны төрле керемнәр дәрәҗәсе буенча һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын оештыру, гражданнар өчен торак алу мөмкинлеген тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек хокукы яисә наем нигезендә даими һәм вакытлыча яшәү өчен торак базарын булдыру.

Программаны гамәлгә ашыру срогы – 2024 ел.

## III. Программа чаралары

Программа түбәндәге чараларны үз эченә ала:

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында, шулай ук махсуслаштырылган оешма аша торак урыннар сатып алуга теләк белдергән һәм махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелә торган аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында Программа чараларын финанслауны гамәлгә ашыру;

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукны гамәлгә ашыручы гаиләгә бала туу вакытында, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренчел һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү;

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру һәм җир кишәрлекләрен махсуслаштырылган оешмага түләүсез файдалануга бирү.

## IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

Программаны гамәлгә ашыру чараларын финанслауга юнәлтелгән чыгымнарның гомуми күләме 18 457,423 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы оешмалары түләүләре исәбеннән Татарстан Республикасы оешмалары һәм Программаны үтәүче арасында төзелгән иганә шартнамәләре һәм килешүләр нигезендә Программа чараларын үтәүгә – 10 961,405 млн.сум;

Программаны үтәүче акчасы исәбеннән – 6 796,018 млн.сум, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фонды белән төзелгән иганә шартнамәсе нигезендә Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен булдыруны финанслауга – 6,319 млн.сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән балалары туган яки уллыкка (кызлыкка) алынган гаиләләргә сатып алына торган торак өчен башлангыч һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә – 700,0 млн.сум.

## V. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны үтәүче аны тулы күләмдә гамәлгә ашыруны оештыра һәм Программаны тормышка ашыру турындагы хисапларны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына кертә.

Программаны гамәлгә ашыруның барышын тикшереп тору аның координаторы - Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

## VI. Программаның икътисади, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

1. Программа түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында гражданнарны торак белән тәэмин итү чараларын, шулай ук махсуслаштырылган оешма аша торак урыннар сатып алу теләген белдергән һәм махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү чараларын 161,7 кв.метр торакны кулланылышка кертеп, 17 757,423 млн. сумнан да ким булмаган күләмдә финансларга;

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукны гамәлгә ашыручы гаиләгә бала туу вакытында, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренчел һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәмен күрсәтү 700,0 млн. сум күләмендә;

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштырырга һәм җир кишәрлекләре махсуслаштырылган оешмага түләүсез файдалануга бирергә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә төзелгән торак күләме 161,7 мең кв.метр тәшкил итәргә тиеш.